МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.12.2025 Казан ш. № 02-256

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 26.12.2024 ел, № 02-121 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, тәгаенләштерү һәм аныклау турындагы күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 26.12.2024 ел, № 02-121 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, тәгаенләштерү һәм аныклау турындагы күрсәтмәләргә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 10.03.2025 ел, № 17-36, 17.06.2025 ел, № 02-112, 12.11.2025 ел, № 02-198, 29.12.2025 ел, № 02-255 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр М.Ж.Фәйзрахманов

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
« 30 » декабрь, 2025 ел,
№ 02-256 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 26.12.2024 ел, № 02-121 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына караган өлешендә Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибен билгеләү, тәгаенләштерү һәм аныклау турындагы күрсәтмәләргә кертелә торган үзгәрешләр

1. «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары исемлеге һәм аларны тиешле максатчан статьяларга кертү кагыйдәләре» 2 пунктында

а) «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.1. пунктчасында:

«01 2 03 00000 «Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү системасын үстерү «региональ проекты» максатчан статьясын төшереп калдырырга;

«01 2 08 00000 «Сәламәт тукланууны һәм зарарлы гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарга сәламәт яшәү рәвешенә этәргеч бирү системасын булдыру» региональ проекты» максатчан статьясын төшереп калдырырга;

«01 2 10 00000 «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» региональ проекты» максатчан статьясын төшереп калдырырга;

«01 4 08 00000 «Социаль әһәмиятле авыруларны кисәтү һәм аларга каршы көрәш» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 17020 Хәмер куллануны һәм тәмәке тартуны киметүне дә кертеп, Россия Федерациясендә яшәүчеләрдә сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча, хәмер һәм тәмәке куллануны киметүне дә кертеп, Россия Федерациясендә яшәүчеләрдә сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән чараларны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

«01 4 11 00000 «Сәламәтлек саклау өлкәсенең кадрлар ресурслары белән идарә итү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен өстәргә:

«- 17000 Табибларга - яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча табибларга - яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 18000 Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч- табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итү

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч-табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97090 Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар

- 97092 Һөнәрнең абруен күтәрү өчен медицина хезмәткәрләре конкурсын үткәрү буенча чара»;

«01 4 12 00000 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының, аңа буйсынучы оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына түбәндәге чыгымнар юнәлешләрен өстәргә:

«- 97040 Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру буенча чаралар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

- 97090 Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар

- 97091 Социаль өлкә хезмәткәрләренә мәҗбүри алдан, вакытлыча медицина тикшерүләре (тикшеренүләр) уздыруны оештыру»;

б) «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.2. пунктчасында «02 2 Ю6 00000 «Педагогика һәм остазлар» федераль проекты» максатчан статьясында « - 50500 Федераль бюджет средстволары хисабына, Татарстан Республикасы дәүләт гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, муниципаль гомуми белем бирү оешмалары директорларының тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән берлектә эшләү буенча киңәшчеләренә айлык акчалата түләү» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән максатларга башка бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларының, Байконур шәһәренең һәм «Сириус» федераль территориясенең дәүләт гомуми белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары, муниципаль гомуми белем бирү оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары директорларының тәрбия һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән берлектә эшләү буенча киңәшчеләренә айлык акчалата түләүләрне тәэмин итүгә бюджетларга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 000 2 02 45050 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

в) «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.3. пунктчасында 03 4 06 00000 «Инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясында «- R5140 «Инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә:

«Күрсәтелгән максатчан субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Инвалидларны реабилитацияләү һәм абилитацияләү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары чараларын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25514 02 0000 150 керемнәр төрләре коды буенча чагылдырыла.»;

г) «Татарстан Республикасын икътисадый үстерү һәм инновацион икътисад» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.10. пунктчасында «11 2 07 00000 «Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар төзү һәм үстерү» региональ проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 60710 «Төньяк капкалар» индустриаль паркы идарәче компаниясенә – «Төньяк капкалар» акционерлык җәмгыятенә индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә субсидияләр.»;

д) «Татарстан Республикасы транспорт системасын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.12. пунктчасында 13 4 04 00000 «Автомобиль, шәһәр электр транспортын үстерү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 03180 Транспорт өлкәсендә гомуми файдаланудагы пассажир транспортының хәрәкәт составын яңартуга юнәлдерелгән гамәлләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча транспорт өлкәсендә гомуми файдаланудагы пассажир транспортының хәрәкәт составын яңартуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.»;

е) «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.13. пунктчасында:

«14 2 20 00000 «Техник һәм технологик модернизация, инновацион үсеш» региональ проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 63504 Өсте ябулы туфракта өстәмә яктырту технологиясен кулланып яшелчә үстерүче авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күчмә сәүдә өчен махсус автотранспорт сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр»;

Түбәндәге максатчан статьяны өстәргә:

«14 2 Е3 00000

«Селекциядә һәм генетикада фәнни эшләнмәләрне үстерү өчен шартлар тудыру» федераль проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча федераль проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 55570 Нәселле терлекчелек өлкәсендә геном селекциясен үстерү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча нәселле терлекчелек өлкәсендә геном селекциясен үстерү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча федераль бюджеттан субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына хәл ителә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Күрсәтелгән максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка субсидияләр» 000 2 02 29999 02 0000 150 керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

ж) «Татарстан Республикасында урман хуҗалыгын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.14. пунктчасында «15 2 Ч6 00000 «Урманнарны саклау» федераль проекты» максатчан статьясында «- 54290 Арендага бирелмәгән урман кишәрлекләрендә, шул исәптән шәһәрләр һәм сәнәгать үзәкләре тирәсендә, урманнарны торгызу мәйданын арттыру буенча федераль бюджет акчалары исәбеннән чаралар үткәрү» чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән максатларга субвенцияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясендә 000 2 02 35429 02 0000 150» арендага бирелмәгән урман кишәрлекләрендә, шул исәптән шәһәрләр һәм сәнәгать үзәкләре тирәсендә урманнарны торгызу мәйданын арттыру буенча чаралар үткәрүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр « керемнәр төре коды буенча чагылдырыла.»;

з) «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.22. пунктчасында:

түбәндәге максатчан статьяны өстәргә:

«26 2 0К 00000
«Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү»
төбәк проекты

Әлеге максатчан статья буенча чыгымнарның тиешле юнәлешләре буенча региональ проектны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла, шул исәптән:

- 72310 Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»;

«26 2 П1 00000 «Номерлар фондын, инфраструктурасын һәм кунакларны җәлеп итү өчен яңа нокталар булдыру» федераль проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен өстәргә:

«- 55581 Татарстан Республикасында туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый башлангычларга дәүләт ярдәме

- 55582 Татарстан Республикасында туризмны үстерүгә юнәлдерелгән вакыйгаи чараларны үткәрүгә ярдәм итү һәм аларны үстерүгә этәргеч бирү

- 55583 Шәһәр үзәгенең туристлык коды нигезендә муниципаль берәмлекнең иҗтимагый территориясен үстерү проектларын гамәлгә ашыру.»;

и) «Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохитен булдыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.27 пунктчасында «35 2 02 00000 «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территорияләрен төзекләндерү» региональ проекты» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 14180 Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасында Төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәмитү фондына субсидия»;

к) «Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.28. пунктчасында «37 4 01 00000 «Спорт чараларын үткәрү, югары класслы спортчыларны әзерләүне тәэмин итү» процесс чаралары комплексы» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 25150 Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган средстволар

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча башка дәрәҗәдәге хакимият органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Күрсәтелгән максатларга җирле бюджетларга бүтән бюджетара трансфертларның керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Бюджетларга тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» 000 2 02 49999 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.»;

л) «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы» 2.29. пунктчасында «38 2 Ю1 00000 «Россия – мөмкинлекләр иле» федераль проекты» максатчан «- 51160 «Яшьләр өчен регион» Россия Федерациясе субъектларында яшьләр сәясәтен комплексלы үстерү программасын гамәлгә ашыруга финанслашыла торган чыгымнар» статьясында чыгымнар юнәлешенең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күрсәтелгән максатларга субсидияләрнең Татарстан Республикасы бюджетына керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Россия Федерациясе субъектларында яшьләр сәясәтен комплекслы үстерү программасын гамәлгә ашыруга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр» 000 2 02 25116 02 0000 150 керемнәр төренең коды буенча чагылдырыла.»;

м) «Татарстан Республикасы бюджеты һәм Россия Федерациясе бюджеттан тыш дәүләт фондлары чыгымнарының программада каралмаган юнәлешләре» 2.32. пунктчасында «99 0 01 00000 Программада каралмаган чыгымнар» максатчан статьясына чыгымнарның түбәндәге юнәлешен өстәргә:

«- 63990 «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне бүләкләүгә дотацияләр

Чыгымнарның әлеге юнәлеше буенча «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия конкурсында җиңүчеләрне бүләкләүгә федераль бюджеттан дотацияләр хисабына башкарыла торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары чагылдырыла.

Күрсәтелгән максатларга дотацияләрләрнең керүе бюджетлар керемнәре классификациясенең «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия конкурсы җиңүчеләрен бүләкләүгә бюджетларга дотацияләр» 000 2 02 15399 00 0000 150 керемнәр төренең тиешле кодлары буенча чагылдырыла.».

2. 2нче кушымтада:

а) юлларны

| | |
|---|---|
| «01 2 03 00000 | Региональный проект «Развитие системы оказания первичной медико-санитарной помощи» |
| 01 2 03 97040 | Мероприятия по организации проведения диспансеризации государственных гражданских служащих Республики Татарстан |
| 01 2 03 97090 | Мероприятия, проводимые в рамках системы здравоохранения |
| 01 2 03 97091 | Организация проведения обязательных предварительных, периодических медицинских осмотров (обследований) работников социальной сферы |
| 01 2 08 00000 | Региональный проект «Формирование системы мотивации граждан к здоровому образу жизни, включая здоровое питание и отказ от вредных привычек» |
| 01 2 08 17020 | Мероприятия, направленные на формирование здорового образа жизни у населения Российской Федерации, включая сокращение потребления алкоголя и табака» |

төшереп калдырырга;

б) юлларны

| | |
|---|---|
| «01 2 10 00000 | «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» региональ проекты |
| 01 2 10 17000 | Табибларга - яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү |
| 01 2 10 18000 | Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч-табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итү |
| 01 2 10 97090 | Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар |

| | |
|---|---|
| 01 2 10 97092 | Һөнәрнең абруен күтәрү өчен медицина хезмәткәрләре конкурсын үткәрү чаралары» |

төшереп калдырырга;

в) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 08 03820 | Кеше иммунодефициты вирусларын, шул исәптән B һәм (яисә) C гепатитлары вирусларын йоктырган затларны ачыклау һәм дәвалауны мониторинглау өчен диагностика чаралары сатып алуларны финанс белән тәэмин итү» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 08 17020 | Хәмер куллануны һәм тәмәке тартуны киметүне дә кертеп, Россия Федерациясе халкының сәламәт яшәү рәвешен булдыруга юнәлдерелгән гамәлләр»; |

г) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 11 00000 | «Сәламәтлек саклауның кадрлар ресурслары белән идарә итү» процесс чаралары комплексы» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 11 17000 | Табибларга -яшь белгечләргә социаль ярдәм чараларын финанс белән тәэмин итү |
| 01 4 11 18000 | Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алган белгеч табибларга, клиник-лаборатор диагностика табибларына дәүләт ярдәме чараларын финанс белән тәэмин итү»; |

д) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 11 97030 | Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка чаралар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 11 97090 | Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар |
| 01 4 11 97092 | Һөнәрнең абруен күтәрү өчен медицина хезмәткәрләре конкурсын үткәрү чаралары»; |

е) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 12 97030 | Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка чаралар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 97040 | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру чаралары»; |

ж) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «01 4 12 97070 | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «01 4 12 97090 | Сәламәтлек саклау системасы кысаларында үткәрелә торган чаралар |

| | |
|---|---|
| 01 4 12 97091 | Социаль өлкә хезмәткәрләренә мәҗбүри алдан, вакытлыча медицина тикшерүләре (тикшеренүләре) уздыруны оештыру»; |

з) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «11 2 07 00000 | «Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар булдыру һәм үстерү» региональ проекты» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «11 2 07 60710 | «Төньяк капкалар» индустриаль паркы идарәче компаниясенә – «Төньяк капкалар» акционер җәмгыятенә индустриаль парклар инфраструктурасы объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә субсидияләр»; |

и) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «13 4 04 03170 | Транспортның башка төрләре өлкәсендә аерым чаралар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «13 4 04 03180 | Транспорт өлкәсендә гомуми файдаланудагы пассажир транспортының хәрәкәт составын яңартуга юнәлдерелгән гамәлләр»; |

к) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 2 20 63503 | Юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга терлек азыгы үзәкләре өчен фасовкалау линиясенә ия булган технологик җайланмалар сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 2 20 63504 | Өсте ябулы туфракта өстәмә яктырту технологиясен кулланып яшелчә үстерүче авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күчмә сәүдә өчен махсус автотранспорт сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр»; |

л) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «14 2 Е2 55740 | Оешмаларның фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен һәм (яисә) тәҗрибә-конструкторлык эшләрен башкаруга, мондый оешмалар тарафыннан инновацион-технологик проектларны гамәлгә ашыру кысаларында, чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «14 2 Е3 00000 | «Селекциядә һәм генетикада фәнни эшләнмәләрне үстерү өчен шартлар тудыру» федераль проекты |
| 14 2 Е3 55570 | Нәселле терлекчелек өлкәсендә геном селекциясен үстерү чараларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча финанслашыла торган чыгымнар»; |

м) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «26 2 01 13979 | Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсендә волонтерлыкка ярдәм итү чаралары комплексын гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «26 2 0К 00000 | «Социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» региональ проекты |
| 26 2 0К 72310 | Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) милкендәге социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм капиталь ремонт»; |

н) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «26 2 П1 55580 | «Туризмны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы күрсәткечләренә ирешүгә бердәм субсидия кысаларында финанслашыла торган чыгымнар» |

түбәндәге эчтәлектәге юлларны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «26 2 П1 55581 | Туристлык инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән иҗтимагый башлангычларга дәүләт ярдәме |
| 26 2 П1 55582 | Татарстан Республикасында туризмны үстерүгә юнәлдерелгән вакыйгаи чараларны үстерүгә ярдәм итү һәм аларны үстерүгә этәргеч бирү |
| 26 2 П1 55583 | Шәһәр үзәгенең туристлык коды нигезендә муниципаль берәмлекнең иҗтимагый территориясен үстерү проектларын гамәлгә ашыру»; |

о) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «35 2 02 14160 | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә парклар һәм скверлар төзү һәм төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыру» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «35 2 02 14180 | Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын гамәлгә ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасында Төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм фондына субсидия»; |

п) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «37 4 01 12970 | Югары казанышлар спорты өлкәсендә физик культура һәм спорт чаралары» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «37 4 01 25150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары кабул иткән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен тапшырыла торган акчалар»; |

р) юлдан соң

| | |
|---|---|
| «99 0 01 57010 | Җәмәгать тәртибенә һәм җәмәгать иминлегенә яный торган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча тапшырылган вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруга федераль бюджетка субвенцияләр» |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | |
|---|---|
| «99 0 01 63990 | «Иң яхшы муниципаль практика» Бөтенроссия конкурсы җиңүчеләрен бүләкләүгә дотацияләр». |